СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2021 г.Зеленодольск № 73

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **кабул итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган,Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның 2 пунктындагы 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) Устав проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, Уставка Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелү очракларыннан тыш;»;

1.2. 6 статьяның 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Гавами тыңлаулар, җәмәгать фикер алышулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләмәсен дә кертеп, муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.»;

1.3.17 статьяның 1 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә: «әлеге статьяның 1.1 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш;»;

1.4. 17 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

«1.1. Территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, җәмәгать фикер алышулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.»;

1.5. 19 статьяның 5 пунктындагы 1 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

1.6. 19 статьяның 5 пунктындагы 5 абзацында «территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеге» сүзләрен «территорияне комплекслы үстерү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**